# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Коноваловка авыл җирлеге составына кергән Иске Ашпала торак пунктында
халык җыены нәтиҗәләре турында

**08.11.2020ел.** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 08 ноябрендә, 11.00 сәгатьтә узган халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе түбәндәге мәсьәлә буенча төзелде: "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Иске Ашпала торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1375 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?":

- Иске Ашпала торак пунктына вак таш сатып алу һәм грейдерлау (эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- Иске Ашпала торак пунктында җәйге чорда торак пункт эчендә территориянең үләнен чабу.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 24 халык җыенында катнашучы кертелгән, халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 24 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 24 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Иске Ашпала торак пунктында халык җыены узуын таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Иске Ашпала торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1375 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?" мәсьәләсе буенча карарны таныргa һәм түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- Иске Ашпала торак пунктына вак таш сатып алу һәм грейдерлау (эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- Иске Ашпала торак пунктында җәйге чорда торак пункт эчендә территориянең үләнен чабу.

3. Коноваловка авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында рәисле итүче,**
**Минзәлә муниципаль районы**
**Коноваловка авыл җирлеге Башлыгы** **С.Ә. Билалова**